Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
“Котлы-Бүкәш урта гомуми белем мәктәбе”

# ***Туган телне саклау- безнең бурыч***


Проектның авторы:

11 нче сыйныф укучысы

Дмитриева Анастасия

Җитәкчесе: Гайсина Г.Г.


2026 нчы ел

## Проектның максаты

Яшь буын арасында татар телен өйрәнүгә һәм куллануга кызыксыну булдыру

## Проект эшемә түбәндәге бурычлар куйдым

- Татар теленең иҗтимагый тормышта кулланылышын арттыру, аның буыннан-буынга күчеп, киләчәктә саклануын тәэмин итү
- Телне өйрәнү өчен төрле кушымталар булдыру һәм алардан файдалану кирәклеген ассызыклау.
- Мәдәни мирасны саклау

## Эшемнең актуальлеге

Безнең телебез тарихыбыз шикелле бөек, олы язмышлы. Үз телен белгән кеше генә аның моңын, аһәңен аңлый, тоемлый. Ләкин көндәлек тормышта телебезнең куллану даирәсе кимегәннән - кими бара, татар сүзләрен рус телендәге сүзләр белән алыштырып куллану нәтиҗәсендә телебез ярлылана бара. Татар гаиләләрендә тәрбияләнүче балалар да үз телләрендә сөйләшми. Бу хәтта авыл җирендә яшәүче гаиләләрдә дә күзәтелә. Мәктәпләрдә татар теле дәресләре кими. Алга таба безне нәрсә көтә? Билгеле, телебезгә игътибарсыз, ваемсыз караш күңелне рәнҗетә.

Телебезне өйрәнми башлаган көннән

башлап без бетә башлаячакбыз

*Садри Максуди*

Дөньяда бик күп телләр бар, ләкин һәр кеше өчен иң матур һәм иң яраткан тел – ул аның *туган теле*. Туган тел аша без дөнья белән танышабыз. Ул – белемнең һәм акылның саклаучысы. Туган-үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә. Туган тел хезмәт белән бергә кешене үстерә, аңа Ватанның тарихын белергә, милли сәнгатен аңларга, яратырга ярдәм итә.

Минемчә, ана телен өйрәнү һәм аны саклап калуда гаиләнең роле зур. Татар гаиләсендә һәр әти-әни баласы белән татарча сөйләшергә тиеш. Бүгенге көндә татар милләтенең өмете безгә - киләчәк буынга төбәлгән дип саныйм. Милләтебезне саклау өчен безгә телебезне киләчәк буыннарга тапшырырга, туачак балаларыбызга гореф – гадәтләребезне сеңдерергә, туган телебезне якларга кирәк.

Үз йөзен югалтырга теләмәгән татар кешесе хәзерге заманда туган телен дә, рус телен дә, кирәксә инглиз, француз телләрен дә белергә тиеш. Мин бүген дөньякүләм интернет челтәренә, шуның аша аралашуга зур өметләр баглыйм. Цифрлаштыру шартларында татар теленә кызыксыну уяту чараларының берсе – белем бирү процессына мәгълүмати технологияләр кертү.

Республиканың дәүләт программалары кысаларында татар телендә интерактив проектлар, мобиль кушымталар һәм компьютер программалары булдырдырылган. Бары тик аларны кулланырга гына кирәк.


# Ата-аналар һәм бигрәк тә балалар өчен файдалы интернет-ярдәмлекләр


- www.ganiev.org
- www.бала.рф
- www.tatarschool.ru
- www.tatarhistory.ru
- www.balasuzlek.ru
- www.tatargalyame.kpfu.ru h.б.
















**Бу ресурслардан файдалану уку процессын мавыктыргыч уенга әверелдерә.**


# Татар телен өйрәнү буенча онлайн-дәресләр, платформалар


- anatele.ef.com
- beztatarlar.ru
- selam.tatar
- Әйдә Online һ.б








# Инновацион проектлар




«Тамыр/Тамырлар» - проекты үзендә алдынгы методикаларны һәм интерактив технологияләрне берләштергән уникаль укыту юлын тәшкил итә.

«Әлбәттә» проектында хәзерге көн күренекле татар галимнәренең татар халкы тарихы, тел белеме, әдәбияты, сәнгате һәм фольклорына кагылышлы кыска видеолекцияләре тәкъдим ителә.




Дәрестән тыш чараларда куллану өчен электрон белем бирү чыганагы

Республика халыклары телләрен саклауга һәм үстерүгә татар һәм рус телләре буенча үткәрелә торган халыкара олимпиадалар, «Илһам» язучылар конкурсы, мәктәп театрлары фестивале, якшәмбе мәктәпләре слеты, фәнни-гамәли конференцияләр һәм олимпиадалар, төбәкара профильле тел лагерьлары һәм башка чаралар зур йогынты ясый дип саныйм. Һәм үзем дә әлеге чараларда бик теләп катнашам.










Т. Миннуллин исемендәге фәнни-гамәли конференция




Халыкара туган тел көне



Якташ язучылар белән очрашу

Проект эшемне Ф.Сафинның шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Туган телем – Татар теле!

Һәрбер татарга дәшәм:

Мин сөйләшсәм, син сөйләшсәң,

Без сөйләшсәк –

Туган тел мәңге яшәр!

Димәк, туган телне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – безнең изге бурычыбыз.